КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 сентябрь г.Казань № 728

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру өчен кирәкле документлар формаларын раслау хакында» 2008 ел, 31 гыйнвар, 57 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру өчен кирәкле документлар формаларын раслау хакында» 2008 ел, 31 гыйнвар, 57 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 8 октябрь, 914 нче, 2020 ел, 24 февраль, 131 нче, 2021 ел, 22 сентябрь, 900 нче, 2022 ел, 8 февраль, 99 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Исәпкә алу эшен алып бару тәртибендә:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина оешмасыннан медицина белешмәсе - гражданның гаилә составында аның белән бер фатирда бергә яшәү мөмкин булмаган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан бирелгән вәкаләткә ия башкарма хакимият федераль органы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты

нигезендә билгеләнгән исемлектә каралган хроник авыруның авыр формасы белән интегүче авыру булганда;»;

егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«м) социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу турында яисә исәпкә алудан баш тарту турында вәкаләтле орган карары;»;

егерме дүртенче абзацка «торак урында» сүзләренә кадәр «, социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган» сүзләрен өстәргә;

егерме бишенче абзацка «торак урында» сүзләренә кадәр «, социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган» сүзләрен өстәргә;

әлеге  карар белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәпкә алу өчен гариза формасында «аның белән бер фатирда бергә яшәү мөмкин булмаган» сүзләрен «аның белән бер фатирда бергә яшәү мөмкин булмаган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан бирелгән вәкаләткә ия башкарма хакимият федераль органы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин